| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Центральная , д. 2а, д.Нижние Аты<br>Арский муниципальный район, 422016 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>Үзәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы, Арча муниципаль районы, 422016 |
|---|---|
| Тел. (84366)50-7-35, факс (84366)50-7-35. E-mail: Sat.Ars@tatar.ru | |



**КАРАР**

| | « | 24 | » | сентябрь | 2018 ел | | №17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта АТЫ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

- Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

Сез 2019 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Тубән Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә,түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Тубән Аты , Урта Аты ,Урта Сәрдә,Клачы авылларында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.
- Тубән Аты Һәм Урта Сәрдә авылларында рөхсәтсез чүплекләрне күмү һәм бетерү.

2. Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Клачы авылында мотопомпа сатып алу;

- Түбән Аты, Урта Аты (һәр торак пунктта берәр янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру;;
- Урта Сәрдә авылында янгын савытын сатып алу һәм урнаштыру.
3. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Түбән Аты,Урта Сәрдә, Урта Аты, Клачи авылларында юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш җәю. - юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш түшәү ?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Атыавыл җирлеге башлыгы: Батталова Р.Х